**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“27” ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Югары Көек торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Югары Көек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Югары Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куаклар кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Югары Көек авылында су алу өчен кое урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Югары Көек авылында су алу урыннарында будкалар урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Югары Көек авылы чишмәсен ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Югары Көек авылы урам юлларын кардан грейдлау, чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү). мәсьәләләрен кабул итәргә.

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләләрен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Югары Көек авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.